РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 сентября 2019 года г.Кукмор № 241

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

2003 елның 06 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлеше нигезендә, Кукмара муниципаль районы Уставына таянып, Кукмара муниципаль районы Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре Советларының әлеге авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында:

авыл җирлекләренең генераль планнарын, Җир биләмәләреннән файдалану һәм авыл җирлекләренең төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең генераль планнары нигезендә территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны раслау, авыл җирлекләренең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы составына керүче авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы Килешүнең типлаштырылган формасын расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кушымта буенча типлаштырылган форма нигезендә тапшыру турында килешүләр төзергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 19.09.2009 ел, № 241 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл җирлекләре ______________________ җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

килешү

Кукмара шәһәре «____»_______2018 ел

Татарстан Республикасының Кукмара муниципаль районы Башлыгы _____________________________________, алга таба «Район башлыгы» дип аталучы, Устав нигезендә эш итүче, бер яктан, һәм авыл җирлеге Уставы нигезендә эш итүче, алга таба «Җирлек башлыгы» дип аталучы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының ________________________авыл җирлеге башлыгы ________________________, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге Килешү төзеде:

1. Килешү предметы:

Әлеге Килешүнең предметы булып районның җирле үзидарә органнары тарафыннан җирлектәге җирле үзидарә органнарына түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру тора:

авыл җирлекләренең Генераль планнарын, җир биләмәләреннән файдалану һәм авыл җирлекләренең төзелеш кагыйдәләрен раслау, авыл җирлекләренең Генераль планнары нигезендә территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны раслау, авыл җирлекләренең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1.Районның җирле үзидарә органнары җирлек җирле үзидарә органнарына тапшырырга тиеш:

әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларын (алга таба – вәкаләтләр);

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат.

2.2. Районның җирле үзидарә органнары хокуклы:

әлеге Килешүнең 4.1-4.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә, җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән вәкаләтләрнең үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларының максатчан кулланылышын контрольдә тотарга;

авыл җирлеге җирле үзидарә органнарыннан әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүматны алырга.

2.3. Җирлекнең җирле үзидарә органнары бурычлы:

закон таләпләре нигезендә вәкаләтләрне тормышка ашырырга, шул исәптән районның җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән финанс чараларыннан бары тик вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында гына файдалануны тәэмин итәргә,

район җирле үзидарә органнарына вәкаләтләрне үтәү турында квартал саен хисаплар, шулай ук Килешү предметына кагылышлы аерым мөрәҗәгатьләр буенча башка мәгълүматлар бирергә,

2.4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары хокуклы:

вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен районның җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган финанс чараларын алырга һәм кулланырга; район җирле үзидарә органнарыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен законлы рәвештә башка матди ресурсларны һәм финанс чараларын өстәмә кулланырга.

## 3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе

3.1.Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

3.2.Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме елга _____________ сум күләмендә билгеләнә.

3.3.Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан финанс чараларын максатчан файдаланмаган очракта, алар районның җирле үзидарә органнары таләбе буенча ун көн эчендә район бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

## 4. Вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тоту

4.1.Кукмара муниципаль районының Башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, Җирлек башкарма комитетыннан тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында кирәкле мәгълүмат һәм әлеге килешүнең кушымтасы нигезендә хисап соратып ала.

4.2.Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты соратуы буенча җирлек башкарма комитеты соратып алына торган мәгълүматны бирә һәм, айның хисап кварталыннан соң килүче 10 нчы числосыннан да соңга калмыйча, әлеге килешүгә кушымта нигезендә квартал отчетларын төзи һәм тапшыра.

4.3.Тапшырылган финанс чараларын сарыф итүне контрольдә тоту Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тарафыннан, шул исәптән Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты соратуы буенча да башкарыла.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

5.1.Килешү Яклар кул куйган көннән үз көченә керә һәм 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

5.2.Килешү Якларның берсе дә аның өзелүе турында әлеге килешүнең 5.1 пунктында каралган вакыт чыкканчы 30 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итмәсә, 2020 елга озайтылган дип санала.

## 6. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

6.1.Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта бер яклы тәртиптә.

Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә икенче Якка язма рәвештә аның гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы 30 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

6.2.Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, җирлекнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын районның җирле үзидарә органнарына кире кайтаралар.

7. Якларның җаваплылыгы

7.1.Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җавап тотуга нигез булып торырга мөмкин.

7.2.Әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як икенче Якка әлеге килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

7.3.Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне алга таба үтәүдән азат итми.

8 нче маддә. Бәхәсләрне чишү тәртибе

8.1.Әлеге килешүне үтәү белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары үткәрү юлы белән хәл ителә.

8.2.Бәхәсне сөйләшүләр яисә килештерү процедураларын үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаганда, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Килешүгә якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.1.Килешү тигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

10. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Кукмара муниципаль районы<br>Башлыгы | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы ______________<br>авыл җирлеге башлыгы |
| __________ _________________ | ___________ ___________________ |

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына
Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле
үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге аерым
мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен
тапшыру турында» Килешүгә Кушымта

**Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Кукмара муниципаль районы авыл җирлеге бюджетларына башка бюджетара трансферттан файдалану турында 2019 елга җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы отчеты**

| Муниципаль берәмлек исеме | | | |
|---|---|---|---|
| | Бүлеп бирелгән | 1 числога үзләштерү (килешү яки дәүләт контрактына кул куелды, ягъни бюджет йөкләмәсе кабул ителде) | 1 нче числога касса чыгымы |
| | | | |
| **Барлыгы:** | **0** | **0** | **0** |

Җитәкче
МП